**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 декабрендәге 4799 номерлы карары**

**«2026 – 2028 елларга Казан шәһәрендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында**

Казан шәһәре территориясендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру, экстремизм һәм террорчылык күренешләренең нәтиҗәләрен киметү һәм бетерү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 14 статьясы (2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында»гы федераль закон (2025 елның 23 июлендәге 215-ФЗ номерлы федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы «Террорчылыкга каршы тору турында»гы федераль закон (2023 елның 10 июлендәге 287-ФЗ номерлы федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 28 декабрендәге 1124 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясе, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2023 елның 30 декабрендәге пр-2610 номерлы әмере белән расланган Россия Федерациясендә 2024 – 2028 елларга террорчылык идеологиясенә каршы торуның комплексլы планы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары (2023 елның 10 августындагы 2246 номерлы карары редакциясендә) нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә «2026-2028 елларга

Казан шәһәрендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау» муниципаль программасын (алга таба – муниципаль программа) расларга:

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының тармак (функциональ) һәм территориаль органнары, Казан шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы башка оешмалар җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2.1. программаның 1 номерлы кушымтасы нигезендә муниципаль программаны гамәлгә ашыру чараларын үтәүне;

2.2. ведомство программалары чикләрендә башкарыла торган чараларны һәм финанслау күләмнәрен исәпкә алып, муниципаль программаның үтәлеше турында программаның 3 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча квартал саен Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына хисап тапшырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына:

3.1. квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 20 нче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә әлеге карарның 2 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга;

3.2. ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат тапшырырга;

3.3. муниципаль программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәрен үзгәртү буенча тәкъдимнәрне билгеләнгән тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә тапшырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 25 маендагы 2128 номерлы «2016-2020 елларга Казан шәһәрендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау муниципаль программасы турында»гы карарын (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5316 номерлы, 2017 елның 4 апрелендәге 976 номерлы, 2018 елның 5 февралендәге 491 номерлы, 2018 елның 26 февралендәге 749 номерлы, 2018 елның 8 августындагы 4328 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге

5933 номерлы, 2019 елның 13 маендагы 1705 номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 2711 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 3986 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 3983 номерлы, 2022 елның 27 гыйнварындагы 270 номерлы, 2023 елның 25 июлендәге 2088 номерлы, 2023 елның 19 декабрендәге 4172 номерлы, 2025 елның 7 мартындагы 628 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 30 декабрендәге
4799 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**«2026-2028 елларга Казан шәһәрендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау» муниципаль программасы**

**Муниципаль программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | «2026-2028 елларга Казан шәһәрендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба – муниципаль программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты |
| Муниципаль программаның координаторы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты |
| Программаның төп башкаручылары | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» префектурасы, Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитиак идарәсе (килешү буенча), Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе, Казан |

| | |
|---|---|
| | шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте (килешү буенча), Татарстан митрополиясе епархиясе (килешү буенча), «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), идарәче торак компанияләре (килешү буенча), Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе (килешү буенча), РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Транспорттагы Казан линия идарәсе (килешү буенча), «Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җинаять-башкарма инспекциясе» федераль казна учреждениесе (килешү буенча), Россия Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү |

| | |
|---|---|
| | буенча), Росгвардиянең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Баш идарәсе (килешү буенча), Казан шәһәре буенча дәүләт янгын күзәтчелеге органнары (килешү буенча), Татарстан халыклары ассамблеясе (килешү буенча), «“Навигатор” яшьләр инновацион һәм профилактик программаларының республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча), иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр (килешү буенча), муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр җитәкчеләре (килешү буенча), объектлар (учреждениеләр, оешмалар) җитәкчеләре (килешү буенча), кешеләр күп була торган объектлар җитәкчеләре (килешү буенча) |
| Муниципаль программаның максатлары һәм бурычлары | Муниципаль программаның максаты – экстремизм һәм террорчылыкны профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү, Казан шәһәрендә яшәүче кешеләрнең тормышын экстремистик һәм террористик күренешләрдән саклау, халыкта Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә террорчылык идеологиясен кабул итмәү һәм аны пропагандалауга карата бирешмәүчәнлек формалаштыру.<br>Муниципаль программаның бурычлары:<br>- экстремизм һәм террорчылык күренешләрен кисәтү буенча профилактик чараларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү;<br>- халыкның экстремистлык һәм террорчылык идеологиясе күренешләре белән килешмәве атмосферасын булдыруга юнәлдерелгән иҗтимагый фикер формалаштыру;<br>- экстремизм һәм террорчылык күренешләрен кисәтү; |

| | |
|---|---|
| | - тормышны тәэмин итү объектларының һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы саклануын көчәйтү |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2026 – 2028 еллар.<br>Программа бер этапта тормышка ашырыла |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән финанслау күләме | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруга Казан шәһәре бюджетыннан 5,64 млн сум каралган, шул исәптән:<br>- 2026 елда – 1,88 млн сум;<br>- 2027 елда – 1,88 млн сум;<br>- 2028 елда – 1,88 млн сум.<br>Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында һәм аңа, Казан шәһәре бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелә. Әгәр дә әлеге программада каралмаган чыганаклардан өстәмә акча җәлеп ителсә, программа заказчысы тиешле үзгәрешләр кертә. Башка финанслау чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин |
| Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Муниципаль программа радикаль идеологияләргә каршы торучы куркынычсыз мохит булдыруга юнәлтелгән.<br>Көтелгән нәтиҗәләр:<br>- экстремистик юнәлештәге җинаятьләрнең гомуми санында көч куллану характерындагы җинаятьләр өлешен киметү;<br>- Казан территориясендә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында һәм, Интернет челтәрен дә кертеп, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә экстремистик материаллар таралуын чикләү;<br>- халыкның протест активлыгын киметү, Казан шәһәрендә милләтара (этникара) һәм |

| | |
|---|---|
| | конфессияара киеренкелекне киметү;<br>- хакимият органнары, хокук саклау органнары һәм җәмәгать оешмаларының үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- гражданлык җәмгыяте институтларының (шул исәптән социаль юнәлешле һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларның) экстремистик күренешләрне профилактикалау һәм кисәтүдә актив катнашуы;<br>- гражданлык җәмгыяте институтларын радикаль иҗтимагый төркемнәр эшчәнлегеннән яклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>- җәмгыятьтә, бигрәк тә яшьләр арасында экстремистик эшчәнлеккә түземсезлек, экстремистик идеологияне кабул итмәүне формалаштыру;<br>- халыкның, аеруча яшьләрнең радикальләшү дәрәҗәсен киметү;<br>- экстремистлык һәм террорчылык куркынычы турында хәбәрдарлыкны арттыру;<br>- этнослар һәм диннәр арасындагы татулыкны ныгыту;<br>- экстремизмны профилактикалау буенча яшьләрнең позитив инициативалары санын арттыру;<br>- гражданнарны һәм җәмгыятьне экстремистик күренешләрдән яклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>- Казан шәһәре халкын, шул исәптән яшь буынны, экстремистик идеология таралудан һәм йогынтысыннан саклау;<br>- җәмгыятьтә ксенофобия дәрәҗәсен киметү;<br>- халыкның, аеруча яшьләрнең радикальләшүен киметү;<br>- мәгълүмат киңлегенең куркынычсызлыгын арттыру;<br>- экстремизмга каршы юнәлтелгән теле- һәм видеоязмалар (кыска метражлы фильмнар) |

| | |
|---|---|
| | төшерү һәм аларны, Интернет челтәрен дә кертеп, телеканаллар эфирында, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә урнаштыру;<br>- җәмгыятьтә, аеруча яшь буын арасында, патриотлык рухын күтәрү;<br>- гомумроссия гражданлык тиңдәшлеге нигезендә җәмгыятьнең бердәмлеген һәм берләшүен ныгыту;<br>- Татарстан халыкларының тарихи мирасын һәм милли үзенчәлеген саклау;<br>- Россия тарихы белән кызыксыну дәрәҗәсен күтәрү һәм тарихи фактларны бозуга юл куймау;<br>- чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан кылынган экстремистик юнәлештәге җинаятьләр һәм хокук бозулар санын киметү;<br>- массакүләм мәгълүмат чараларында экстремистик материаллар, экстремистик эшчәнлекне гамәлгә ашырырга өндәүләр, экстремистик һәм террорчылык эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезләү һәм (яисә) аклау булган мәгълүмат таратуның ачыкланган фактлары санын киметү;<br>- Казан шәһәрендә дә, тулаем республикада да милләтара (этникара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышына халык тарафыннан куела торган бәяне күтәрү |

## I. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, төп мәсьәләләр һәм аларны хәл итү юллары

2016-2025 елларга Казан шәһәрендә экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау муниципаль программасының эш барышында җирле үзидарә органнарының экстремизмны һәм террорчылыкны, милли һәм раса түземсезлеген профилактикалау, этник дискриминациягә каршы тору,

интернационализм культурасын, милли һәм дини түземлелекне тарату; милләтче экстремистик яшьләр төркемнәре оешуга һәм аларның эшчәнлегенә юл куймау буенча эш формаларын һәм алымнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән программа чаралары комплексы гамәлгә ашырылды.

Экстремизм һәм террорчылык җәмәгать куркынычсызлыгына реаль куркыныч тудыра һәм җәмгыять тормышының барлык өлкәләренә тискәре йогынты ясый.

2025 ел башыннан Казанда террорчылыкка каршы комиссиянең 9 утырышы уздырылды, 67 вазифаи зат тыңланды, 3 яңа норматив-хокукый акт кабул ителде, профилактик эш буенча 31 актуаль мәсьәлә каралды һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру, шулай ук экстремистик һәм террорчылык күренешләренә юл куймау буенча чаралар эшләнде.

Куркыныч янаганда яисә террорчылык акты кылынганда гамәлләргә әзерлекне тәэмин итү кысаларында, шулай ук Казан шәһәрендә террорчылык һөҗүмнәрен локальләштерү һәм нәтиҗәләрен бетерү өчен көчләрне һәм чараларны әзерләү максатыннан террорчылыкка каршы комиссия секретаре тарафыннан уку-укыту күнекмәләрен уздыру өчен документлар эшләнде һәм алар Татарстан Республикасының Террорчылыкка каршы комиссиясе белән килештерелде.

Соңгы вакытта, аеруча махсус хәрби операция үткәрү шартларында, Казан шәһәре һәм тулаем республика территориясендә экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору өлкәсендә вәзгыять кискенләште. Сәнәгать һәм тимер юл инфраструктуралары объектларына, административ биналарга һәм башка объектларга Украина махсус хезмәтләре мәнфәгатьләрендә эш итүче затлар, Россиягә каршы йогынты астында булган нацист идеологиясе тарафдарлары, шулай ук махсус хәрби операцияне һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте алып бара торган сәясәтне хупламаучы затлар тарафыннан ут төртү фактлары ешайды. Полиция хезмәткәрләре даими нигездә экстремистик яки террорчылык эшчәнлегенә катнашы булган затларны ачыклауга һәм аларны җаваплылыкка тартуга юнәлдерелгән эш алып бара.

2025 елның узган чорында Казанда 65 каршылык чарасы узды (2024 елның шул ук чорында – 81 чара), аларда 1001 кеше катнашты. Нацистлар атрибутикасын яки символикасын пропагандалау һәм ачык демонстрацияләүнең (яки экстремистик оешмаларның атрибутикасын яки символикасын ачык демонстрацияләүнең) 22 факты ачыкланды, 26 кеше административ җаваплылыкка тартылды.

Деструктив характердагы мәгълүмат урнаштырылган сайтларны ачыклау максатыннан Интернет челтәре күзәтелә. Әлеге сайтлар турында мәгълүматлар Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә җибәрелә. Әлеге интернет-сайтлар буенча чаралар алга таба хокук саклау органнары тарафыннан башкарыла.

Эчке эшләр органнары тарафыннан даими нигездә халыкара экстремистик һәм террорчылык оешмалары ячейкаларын, радикаль дини агымнар тарафдарларын, шулай ук экстремистик яки террорчылык эшчәнлегендә катнашу өчен чит илләргә чыккан затларны ачыклау буенча чаралар үткәрелә.

2025 елның узган чорында шәһәр территориясендә эшләп килүче террорчылык ячейкалары ачыкланмады һәм алар тарафыннан яный торган актуаль куркынычлар юк.

Хәзерге вакытта Казан шәһәре территориясендә 158 дини оешма: 83 мөселман дини оешмасы (81 мәчет һәм 2 мәдрәсә), 51 православие дини оешмасы (храмнар һәм чиркәүләр), 6 иске йолачылар гыйбадәт объекты, башка христиан юнәлеше буенча 15 чиркәү, 1 синагога, бер Бахаи һәм бер Кришна гыйбадәт йортлары эшләп килә.

Террорчылыкка каршы көрәштә теләктәшлек көне һәм «Экстремизмга – юк!» айлыгы кысаларында мөселман уку йортларында җәмгыятьтә радикаль һәм деструктив идеологияләрнең таралуына юл куймауга юнәлдерелгән лекцияләр үткәрелә. Моннан тыш, дини оешмалар җитәкчеләре белән чит илдә дини белем алган затларга, шул исәптән мәхәллә җитәкчеләренә Россия Федерациясенең террорчылык эшчәнлегендә катнашу һәм ярдәм итү өчен җаваплылык билгели торган законнары нигезләмәләрен җиткерү, шулай ук аларга Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен аңлату зарурлыгы белән бәйле эш алып барыла.

2025 елның сентябренә Казан шәһәре территориясендә рәсми рәвештә 12 чит ил диаспорасы теркәлгән. Диаспора рәисләре белән аларның әгъзалары тарафыннан террористик характердагы җинаятьләр, шулай ук экстремистик юнәлештәге җинаятьләр һәм хокук бозулар кылуга юл куймау максатыннан профилактик очрашулар үткәрелә. Казанда экстремистик һәм башка деструктив характердагы фикерләрне ачыклау максатыннан милли-мәдәни оешмалар тарафыннан таратыла торган материалларга даими рәвештә күзәтү үткәрелә.

Хәзерге вакытта Казанда милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр тотрыклы, конфликтлы хәлләр теркәлмәде.

Казан шәһәрендә миграция хәле хокук саклау органнары, дәүләт структуралары, шулай ук Казан шәһәренең Террорга каршы көрәш комиссиясе контролендә тора.

Миграция процессларын профилактик күзәтү максатыннан Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең миграция мәсьәләләре бүлеге, Казан гарнизоны полициясе хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт статистикасы органнарына чит ил гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын яшәү урыны буенча теркәү, шулай ук чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны килү урыны буенча исәпкә кую турында мәгълүмат җибәрелә. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Интерполның милли үзәк бюросы бүлеген дә җәлеп итеп, әлеге гражданнарның террорчылык һәм экстремистлык оешмалары һәм башка деструктив төркемнәр эшчәнлегенә каравы тикшерелә.

2025 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча Казан шәһәрендә (яшәү урыны һәм тору урыны буенча) миграция исәбенә куелган чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар саны 206 964 тән 148 250 кешегә кадәр, ягъни узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 28,4 процентка кимеде, шулардан Казан шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча миграция исәбенә 3 989 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар куелды, бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 10,6 процентка түбәнрәк (4 462); тору урыны буенча 135 990 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар миграция исәбенә куелды, бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 27,5 процентка түбәнрәк (187 663).

2025 ел башыннан миграция законнары өлкәсендә 9 917 хокук бозу очрагы ачыкланды һәм чит ил гражданнарын Россия Федерациясеннән чыгару турында 451 карар кабул ителде.

Казан шәһәрендә яшәүче иң күп сандагы чит ил гражданнары түбәндәге республикалардан килгән: Үзбәкстан – 57 069 кеше, Таҗикстан – 17 324 кеше, Азәрбәйҗан – 3 181 кеше, Кыргызстан – 5 010 кеше һәм Казахстан – 64 кеше.

Шулай ук Казан шәһәре территориясендә террорчылык активлыгы югары булган илләрдән килгән шактый күп чит ил гражданнары яши (барлыгы – 18 850, узган елның шушы чорында – 30 114): Төрекмәнстан – 18 212 (узган елның шушы ук чорында – 28 763), Гыйрак – 257 (узган елның шушы ук чорында – 599), Сүрия – 197 (узган елның шушы ук чорында – 437) һәм Әфганстан – 184 (узган елның шул ук чорында – 315).

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Урта Азия һәм Кавказ дәүләтләреннән чыккан кешеләрнең миграция дәрәҗәсе югары булу Татарстан

Республикасына, шулай ук аның башкаласына экстремистик һәм террорчылык оешмалары белән бәйле затларның үтеп керүенә, халыкның этник һәм конфессиональ балансының үзгәрүенә этәргеч бирә, ә бу исә җәмгыятьтә киеренкелекне арттыруга шартлар тудырачак.

Казанга беренче чиратта террорчылык активлыгы югары булган илләрдән укыту һәм хезмәт миграциясе линиясе буенча килүче чит ил гражданнары халыкара экстремистик, шул исәптән дини төркемнәр тарафыннан вербовка базасы буларак файдаланылырга мөмкин булу сәбәпле, хокук саклау органнары тарафыннан әлеге категориядәге затларга карата кирәкле чараларның тулы комплексы үткәрелде.

Шулай итеп, Казан гарнизоны полициясе хезмәткәрләре тарафыннан 13 685 чит ил гражданы тикшерелде, аның нәтиҗәләре буенча 58 чит ил кешесенә карата аларның тору урыннары буенча профилактик чаралар үткәрелә.

Хокук бозуларны, экстремизм һәм террорчылык күренешләрен кисәтү максатыннан мәгариф учреждениеләрендә (гомуми белем бирү учреждениеләре, колледжлар, махсус урта уку йортлары, югары уку йортлары) хокук саклау органнары белән берлектә яшүсмерләр арасында вәзгыятьне мониторинглау оештырылды, социаль челтәрләр ярдәмендә укучы төркемнәренә деструктив юнәлешле йогынтыны киметүгә, балигъ булмаганнарның җинаять кылуын һәм хокук бозуын, балигъ булмаганнарның үз-үзләрен үтерү һәм аутоагрессив тотышын профилактикалауга, милләтара нигездә килеп чыккан процессларның тискәре йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән чаралар (лекцияләр, әңгәмәләр, түгәрәк өстәлләр) уздырыла.

Аерым игътибар буллингка (яшүсмерләр тарафыннан мыскыл итүгә) дучар булган балигъ булмаганнарны, шулай ук «колумбайн» («скулшутинг») субкультурасы тарафдарларын ачыклау мәсьәләсенә бирелә.

2025 елның хисап чорында Казан шәһәрендә Террорчылыкга каршы көрәш комиссиясе каршындагы экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау буенча ведомствоара эшче төркемнең 4 утырышы үткәрелде, 12 кеше тыңланды.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе полиция бүлекләрендә профилактик исәптә торучы затлар даими нигездә контрольдә тотыла. Исәпкә алуда катнашучы гаиләләрнең балигъ булмаган әгъзаларын экстремистик-террористик юнәлештәге җинаятьләр кылуга җәлеп итүне булдырмау максатыннан аларның социаль челтәрләре күзәтелә, аларның хокукка каршы эшчәнлек кылуга мөнәсәбәте һәм омтылышы ачыклана, белем

биру учреждениеләрендә үз-үзләрен тотышы күзәтелә, тайпылышлар ачыкланган очракта, Казан гарнизоны хезмәткәрләре тарафыннан аларны профилактик исәпкә кую чаралары күрелә.

Килеп туган вәзгыятькә бәйле рәвештә төп көчләр куркыныч тудыручы факторларны вакытында ачыклау һәм нейтральләштерүгә, объектларның һәм территорияләрнең террорчылыктан саклануын көчәйтүгә, террорчылык куркынычы килеп чыкканда гамәлләр кылырга әзерлекне арттыруга юнәлдерелгән.

Шулай итеп, Казанда экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору өлкәсендәге эшчәнлек түбәндәге тышкы куркыныч тудыручы факторларны исәпкә алып башкарыла:

- «Ислам дәүләте» (шул исәптән Украинаның куркынычсызлык хезмәте белән берлектә) кебек халыкара террорчылык оешмаларының Сирия Гарәп Республикасы территориясендә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан затларны, террорчылык эшчәнлегенә катнашы булган затларның балаларын, шулай ук Сүриядән һәм Гыйрак Республикасыннан кайткан балаларны файдаланып, Россия территориясендә террорчылык актлары башкарырга омтылышлары;

- хезмәт һәм легаль булмаган миграция каналлары аша һәм Якын Көнчыгыш, Африка, Үзәк Азия төбәгеннән килгән чит ил студентлары аша үтеп керү юлы белән милли якташлык җәмгыятьләрендә һәм диаспораларда халыкара террорчылык һәм дини-экстремистик оешмалар тарафдарларының үз идеологияләрен таратуы;

- экстремистик һәм террористик идеологияләрне Интернет челтәре (социаль челтәрләр) аша тарату (төп факторларның берсе булып тора һәм көч куллану, нәфрәт, дискриминацияне пропагандалауны, шулай ук тарихи фактларны һәм дини тәгълиматларны бозуны үз эченә ала);

- Украина махсус хезмәтләренең нигездә Интернет челтәре һәм төрле интернет-мессенджерлар ярдәмендә Россия гражданнарын, шул исәптән балигъ булмаганнарны Россия Федерациясе территориясендә диверсияләр һәм террорчылык актлары кылу максатыннан җәлеп итү омтылышлары;

- Россия Федерациясе Украинада махсус хәрби операция (СВО) уздыру сәбәпле, Украина махсус хезмәтләренең һәм милләтчелек формированиеләренең террорчылык акцияләре башкару куркынычы;

- террорчылык һәм экстремистик структураларның социаль-сәяси вәзгыятьне катлауландыру максатыннан үз эшчәнлекләрен активлаштырырга омтылу ихтималы;

- социаль челтәрләрдә террорчылык һәм башка радикаль яшьләр идеологиясе модераторларының һәм тарафдарларының, шул исәптән «колумбайн» («скулшутинг») идеологиясенең активлашуы, шулай ук шактый күп сандагы яшьләрнең хокукка каршы эшчәнлеккә җәлеп ителүгә әзерлеге.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, аноним рәвештә террорчылык янауларын таратучылар һәм куркыныч төркеменә караган, психик тайпылышлары булган һәм агрессив холкы аркасында авыр җинаятьләр, шул исәптән террорчылык характерындагы җинаятьләр кылырга сәләтле затлар шулай ук зур куркыныч тудыра.

Казан шәһәрендә террорчылыкка каршы көрәш өлкәсендәге вәзгыятькә йогынты ясаучы төп эчке куркыныч тудыручы факторлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- икътисадта социаль каршылыкларны тирәнәйтә торган кризис күренешләре (халыкның яшәү дәрәҗәсе түбәнрәк булу һәм социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләр саны арту);

- этник җинаятьчел һәм дини-экстремистик төркемнәр оештыру, милләтара һәм динара низаглар килеп чыгу мөмкинлеге;

- халыкның хокукый белеменең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы (кешеләрне манипуляцияләр алдында көчсез итә торган һәм аларны экстремистик һәм террорчылык оешмаларына яллауны җиңеләйтә торган җитди фактор булып тора);

- Казан шәһәре территориясендә теркәлгән, экстремизмга каршы тору линиясе буенча профилактик исәптә торучы затларның, аларның якын туганнарының (хатыннары, ирләре, абыйлары, апалары, балалары) һәм фикердәшләренең булуы;

- террорчылык һөҗүмнәре ясалырга мөмкин булган потенциаль объектларның, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт объектларының һәм кешеләр күпләп йөри торган урыннарның террорчылыктан саклануының җитешсезлекләре.

## II. Гамәлгә ашыру вакытларын күрсәтеп, муниципаль программаның төп максатлары һәм бурычлары

Муниципаль программаның төп максаты – экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү, Казан шәһәрендә яшәүче кешеләрнең тормышын экстремистик һәм террористик күренешләрдән саклау, халыкта Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә террорчылык идеологиясен кабул итмәү һәм аны пропагандалауга карата бирешмәүчәнлек формалаштыру.

Муниципаль программаның бурычлары:

- экстремизм һәм террорчылык күренешләрен кисәтү буенча профилактик чараларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

- халыкта экстремистик һәм террорчылык идеологиясе чагылышларына түземсезлек атмосферасы тудыруга юнәлдерелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру;

- экстремизм һәм террорчылык күренешләрен кисәтү;

- тормышны тәэмин итү объектларының һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы саклануын көчәйтү.

Муниципаль программаның төп чаралары:

- экстремизм күренешләреннән саклану формалары һәм ысуллары турында халыкка мәгълүмат бирү;

- күпмилләтле Россия җәмгыяте кыйммәтләренә нигезләнеп, халыкны үз-үзен толерантлы тотуга пропагандалау һәм формалаштыру;

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту; халыкның экстремистик һәм террористик күренешләр фактларына түземсезлеген булдыруга юнәлдерелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру;

- экстремистик һәм террористик характердагы күренешләрне кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик чараларның нәтиҗәлелеген арттыру;

- тормышны тәэмин итү объектларының һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы саклануын көчәйтү.

Профилактика эше беренче чиратта түбәндәге категориягә караган кешеләргә юнәлтелгән:

- экстремистик, террорчылык, милләтчелек һәм неонацист оешмалар, төрле деструктив хәрәкәтләр (субкультуралар) идеяләрен уртаклашучы, шулай ук суицидаль тәртипкә, көчләү гамәлләре кылуга омтылышы булу сәбәпле профилактика системасы органнарында һәм учреждениеләрендә төрле формада исәптә торучы яшьләр вәкилләре;

- Россия Федерациясенең яңа субъектларыннан килгән һәм элек Киев режимы контролендә булган территорияләрдә яшәгән гражданнар;

- Россия Федерациясенә хезмәт эшчәнлеген башкару яки укыту өчен килгән мигрантлар, аларның гаилә әгъзалары;

- җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә иң элек экстремистик яки террорчылык эшчәнлеген гамәлгә ашырган өчен җәза үтәүче яки үтәгән затлар;

- террорчылык эшчәнлегенә катнашы булган затларның (гамәлдәге, хөкем ителгән, нейтральләштерелгән) гаилә әгъзалары;

- кораллы конфликт зоналарыннан кайтарылган (килгән) балигъ булмаган затлар.

Муниципаль программаның төп чаралары киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары исемлеге һәм чараларны финанслау әлеге программаның 2 номерлы кушымтасында китерелгән.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2026 - 2028 еллар.

## III. Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Чараларны финанслау нигездә Казан шәһәре бюджеты хисабына тармаклар буенча башкарыла.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруга Казан шәһәре бюджетыннан 5,64 млн сум каралган, шул исәптән:

- 2026 елда – 1,88 млн сум;
- 2027 елда – 1,88 млн сум;
- 2028 елда – 1,88 млн сум.

Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә. Аңа, Казан шәһәре бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Әлеге программада алдан каралмаган чыганаклардан өстәмә чаралар җәлеп ителгән очракта, программаның заказ бирүчесе аңа тиешле үзгәрешләр кертә.

Башка финанслау чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин.

## IV. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмы

Муниципаль программаны планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм башкаруны гомуми контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты гамәлгә ашыра. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру барышында ел саен максатчан күрсәткечләр һәм программа

чараларына чыгымнар, аны гамәлгә ашыру механизмы һәм башкаручылар составы төгәлләштерелә. Чараларны үтәү өчен җаваплы бүлекчәләрдән муниципаль программаны үтәү барышы турында мәгълүмат сорала һәм анализлана.

Чараларны финанслау тармак принцибы буенча башкарыла.

Муниципаль Программаның чараларын гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 нчы көненә кадәр, чараларны башкаручыларга тиешле бюджетлардан бүлеп бирелә торган чараларның үтәлеше һәм үзләштерелгән акчалар турында, үсә бару рәвешендә һәм хисап елы өчен тулаем мәгълүмат тапшыралар.

Муниципаль программаның чараларын башкару турында хисапның типлаштырылган формасы программаның 3 номерлы кушымтасында бирелгән.

Муниципаль программаның координаторы

- хисап кварталыннан соң килүче айның егермесенә кадәр квартал саен, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә муниципаль программаны тормышка ашыру турында билгеләнгән форма буенча хисап тапшыра;

- ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат тапшыра.

## V. Муниципаль программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм көтелә торган ахыргы нәтиҗәләрне тасвирлау

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге әлеге программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

Муниципаль программа радикаль идеологияләргә каршы торучы куркынычсыз мохит булдыруга юнәлтелгән.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре:

- экстремистик юнәлештәге җинаятьләрнең гомуми санында көч куллану характерындагы җинаятьләр өлешен киметү;

- Казан территориясендә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында һәм, Интернет челтәрен дә кертеп, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә экстремистик материаллар таралуын чикләү;

- халыкның протест активлыгын киметү, Казан шәһәрендә милләтара (этникара) һәм конфессияара киеренкелекне киметү;

- хакимият органнары, хокук саклау органнары һәм җәмәгать оешмаларының үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

- гражданлык җәмгыяте институтларының (шул исәптән социаль юнәлешле һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларның) экстремистик күренешләрне профилактикалау һәм кисәтүдә актив катнашуы;

- гражданлык җәмгыяте институтларын радикаль иҗтимагый төркемнәр эшчәнлегеннән яклау дәрәҗәсен күтәрү;

- җәмгыятьтә, бигрәк тә яшьләр арасында экстремистик эшчәнлеккә түземсезлек, экстремистик идеологияне кабул итмәүне формалаштыру;

- халыкның, аеруча яшьләрнең радикальләшү дәрәҗәсен киметү;

- террорчылык һәм экстремистик куркыныч турында хәбәрдарлыкны арттыру;

- этнослар һәм диннәр арасындагы татулыкны ныгыту;

- экстремизмны профилактикалау буенча яшьләрнең позитив инициативалары санын арттыру;

- гражданнарны һәм җәмгыятьне экстремистик күренешләрдән яклау дәрәҗәсен күтәрү;

- Казан шәһәре халкын, шул исәптән яшь буынны, экстремистик идеология таралудан һәм йогынтысыннан саклау;

- җәмгыятьтә ксенофобия дәрәҗәсен киметү;

- мәгълүмат киңлегенең куркынычсызлыгын арттыру;

- экстремизмга каршы юнәлтелгән теле- һәм видеоязмалар (кыска метражлы фильмнар) төшерү һәм аларны, Интернет челтәрен дә кертеп, телеканаллар эфирында, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә урнаштыру;

- җәмгыятьтә, аеруча яшь буын арасында, патриотлык рухын күтәрү;

- гомумроссия гражданлык тиңдәшлеге нигезендә җәмгыятьнең бердәмлеген һәм берләшүен ныгыту;

- Татарстан халыкларының тарихи мирасын һәм милли үзенчәлеген саклау;

- Россия тарихы белән кызыксыну дәрәҗәсен күтәрү һәм тарихи фактларны бозуга юл куймау;

- чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан кылынган экстремистик юнәлештәге җинаятьләр һәм хокук бозулар санын киметү;

- массакүләм мәгълүмат чараларында экстремистик материаллар, экстремистик эшчәнлекне гамәлгә ашырырга өндәүләр, экстремистик һәм террорчылык эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезләү һәм (яисә) аклау булган мәгълүмат таратуның ачыкланган фактлары санын киметү;

- Казан шәһәрендә дә, тулаем республикада да милләтара (этникара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышына халык тарафыннан куела торган бәяне күтәрү.

---

Муниципаль программага
1 номерлы кушымта

**«2026 - 2028 елларга Казанда экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау» муниципаль программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, әлеге программа чаралары буенча финанслау**

<table>
<tr><td colspan="6">Максат: экстремизм һәм террорчылыкны профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү, Казан шәһәрендә яшәүче кешеләрнең тормышын экстремистик һәм террористик күренешләрдән саклау, халыкта Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә террорчылык идеологиясен кабул итмәү һәм аны пропагандалауга карата бирешмәүчәнлек формалаштыру</td></tr>
<tr><td colspan="6">1 нче бурыч. Экстремизм һәм террорчылык күренешләрен кисәтү буенча профилактик чараларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү</td></tr>
<tr><td colspan="6">Индикатор күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td>Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре</td><td>2025 ел<br>(база елы)</td><td>2026 ел</td><td colspan="2">2027 ел</td><td>2028 ел</td></tr>
<tr><td>Казан шәһәре территориясендә террорчылык актларының (башкарырга омтылуның) чагыштырма күләме, процентларда</td><td>0</td><td>0</td><td colspan="2">0</td><td>0</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Төп чараларның атамалары</td><td rowspan="2">Башкаручылар</td><td rowspan="2">Төп чараларны башкару вакыты</td><td colspan="3">Еллар буенча финанслау, млн сумнарда</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td></tr>
<tr><td>1.1. Казан шәһәрендә террорчылыкка каршы көрәш комиссиясенең һәм террорчылыкка каршы көрәш комиссиясенең Казан шәһәре районнарындагы эшче төркемнәренең</td><td>Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре</td><td>2026 – 2028 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| эшчәнлеген оештыру | | | | | |
| 1.2. Казан шәһәрендә террорчылыкка каршы көрәш комиссисенең һәм Казан шәһәре районнары буенча аның эшче төркемнәренең еллык эш планнарын (утырышларның якынча планын) раслау | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.3. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәрендәге террорчылыкка каршы комиссия сәхифәсендә комиссия эшчәнлеге турында мәгълүмат (уздырылган утырышлар, кабул ителгән норматив документлар), программаны гамәлгә ашыру барышында экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалауга ярдәм итә торган үткәрелә торган чаралар турында белешмәләр, фото-, видеоматериаллар, белешмә мәгълүмат урнаштыру, шулай ук террорчылыкка каршы уздырыла торган эшне массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетыАаппараты, Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе (килешү буенча) | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.4. Казан шәһәрендә Террорчылыкка каршы көрәш комиссиясенең мәгълүмат-агарту төркеме кысаларында террорчылык таралуга каршы көрәш буенча халык арасында мәгълүмат җиткерү һәм бу өлкәдәге белемнәрне арттыру эшен оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | Физик культура һәм спорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте (килешү буенча), Татарстан митрополиясенең Казан епархиясе (килешү буенча), «ТАТМЕДИА» АҖ (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | | | | |
| 1.5. Халыкка экстремизм, террорчылык күренешләреннән саклану формалары һәм ысуллары турында мәгълүмат җиткерү эшен оештыру, түбәндәге ысуллар белән:<br>- белешмәлекләрне Казан шәһәренең торак секторында (торак милекчеләре ширкәтләрен исәпкә алып), күпфатирлы йортларның подъездларында, лифтларында, счет-фактураларның арткы ягында, сәүдә | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе, Казан шәһәре | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| объектларында, шәһәр пассажир транспортында, тимер юл, һава һәм су транспорты объектларында урнаштыру;<br>- экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалауга, терактлар янаганда яисә барлыкка килгәндә үз-үзеңне тоту һәм гамәлләр кагыйдәләренә багышланган аналитик һәм методик материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында (шул исәптән электрон) бастырып чыгару;<br>- башка формаларны, шул исәптән электрон элемтә чараларын кулланып, халыкка мәгълүмат җиткерү | Башкарма комитетының Транспорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты, идарәче торак компанияләре (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | | | | |
| 1.6. Муниципаль хезмәткәрләрнең «Экстремизм һәм террорчылыкны профилактикалау» программасы буенча һөнәри дәрәҗәсен күтәрү өчен семинарлар оештыру. | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе (килешү буенча) | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.6.1. «Экстремизмны һәм террорчылыкны кисәтү» квалификация күтәрүдә өстәмә һөнәри белем бирү программасы буенча белем бирүне оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе (килешү буенча) | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.7. Казан шәһәренең мөселман мәхәлләләре эшчәнлеген мониторинглау | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.8. Экстремистик һәм террористик юнәлештәге сәяси, дини, милли һәм яшьләр оешмалары эшчәнлеге турында мәгълүмат җыю һәм анализлау эшен үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.9. Деструктив йогынтыга иммунитеты түбән булган укучыларны ачыклау максатыннан гомуми, урта махсус, һөнәри һәм югары белем бирү учреждениеләрендә, шул исәптән дини юнәлештәге һәм хосусый рәвештә идарә ителә торган мәгариф учреждениеләрендә мониторинглау үткәрү һәм анализ ясау | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.10. Экстремистик (террористик) эшчәнлектә, шул исәптән дини фактор нигезендә, этник диаспоралар һәм мигрантлар бергәлекләре эшчәнлеген анализлау | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.11. Экстремистик һәм террорчылык эшчәнлегенә тартыла торган затларны ачыклау максатыннан чит ил гражданнары | Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Россия | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| тупланып яши торган һәм күпләп була торган урыннарда (хостеллар, кунакханәләр, дини культ объектлары) алар белән профилактик эш алып бару | Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | | | | |
| 1.12. Вандализм, һәйкәлләрне мәсхәрәләү, биналарга һәм башка корылмаларга язулар һәм рәсемнәр ясау, шул исәптән нацист символикасы һәм экстремистик характердагы лозунглар язу фактларын ачыклау, аннары полиция органнарына, Федераль куркынычсызлык хезмәтенә хәбәр итү, шулай ук мондый актларның нәтиҗәләрен бетерү буенча үз вакытында чаралар күрү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Ритуаль хезмәтләр оештыру идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» префектурасы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.13. Вандализм фактларына юл куймау максатыннан Казан шәһәренең Арча һәм Архангельск зиратлары территорияләрендә хәрби каберлекләрне видеокүзәтүне оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.14. Җәмәгать китапханәләре өчен, алар базасында пропаганда чаралары үткәрү максатыннан, террорчылыкка каршы көрәш | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| темасына багышланган әдәбият каталогын эшләүдә катнашу, экстремизмга һәм террорчылыкка каршы көрәш темасы буенча китапханә фондын яңарту | | | | | |
| 1.15. Террорчылык, экстремистлык һәм деструктив характердагы мәгълүматны үз эченә алган, шул исәптән барлыкка килү һәм үсешенең барлык этапларында Россия тарихын фальсификацияли торган, шулай ук аның сәясәтен дискредитацияли торган басмаларны ачыклау һәм аларны фондтан алу юлы белән китапханә фондларын өйрәнү (Россия Федерациясенең яңа субъектлары халкына һәм беренче чиратта яшьләренә пропаганда йогынтысына каршы торуга юнәлдерелгән) | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.16. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең террорчылыкка каршы көрәш комиссияләре белән мәгълүмат алмашуны һәм үзара хезмәттәшлекне оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.17. Республика халкына һәм кунакларына экстремизм һәм террорчылык күренешләреннән саклау формалары һәм ысуллары турында, шул исәптән тимер юл, һава һәм су транспорты объектларында белешмәлекләр урнаштыру юлы белән мәгълүмат бирү эшен оештыру | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының транспортта Казан линиясе идарәсе (килешү буенча) | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |
| 1.18. Гомуми белем бирү, һөнәри һәм югары уку йортларында, шулай ук хезмәт | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф | 2026 – 2028 еллар | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| коллективларында укучылар арасында профилактик чаралар үткәрү юлы белән Интернет челтәрендә экстремистик һәм террористик идеология таралуга каршы тору максатыннан хокук саклау органнарына цифрлы грамоталылыкны арттыру өчен мәгълүмат ярдәме күрсәтүне оештыру | идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | | | | |
